КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 декабрь г.Казань № 1085

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2022 ел, 10 июнь, 548 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында» 2022 ел, 10 июнь, 548 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта татар текстында «реконструкцияләү максатларында» сүзләреннән соң «җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә алмаштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлекләренең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренең базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, җир кишәрлекләре белән алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «имза куелган килешүләр» сүзләрен «имза куелган шартнамә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин